ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№324 от «27» 04 2018 г.

Агач һәм куакларны утырту,
аларны тәрбияләү белән бәйле бәяләрне һәм
чыгымнар нормативын раслау турында

Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү турындагы (02.03.2013 елда кабул ителгән) 01-01-2018 санлы мәгълүматы буенча, "Әйләнә – тирәлекне саклау турындагы" 10.01.2002 ел, №7-ФЗ Федераль законы, "Россия Федерациясе Гражданнар кодексының" 1994 ел, 30 ноябрь, №51-ФЗ 261нче статьясының 2 пунктына, "Россия Федерациясенең Җир кодексына" нигезләнеп, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1.Дәүләт милкендәге, шулай ук муниципаль милек булган җирләрдә үсүче агачларны һәм куакларны үстерү, аларны тәрбияләү өчен булган бәяләр һәм чыгымнар нормативын расларга һәм 1,2,3 номерлы кушымталарда тасвирларга;

Нормативларны билгеләгәндә агачлар үсүче җирнең категориясенә, агачларның биеклегенә, диаметрына карап ( ылыслы агачлар өчен кәүсә диаметры 12 см һәм аннан күбрәк, биеклеге -1,3 метр), (башка төр агачлар өчен кәүсә диаметры 16 см һәм аннан күбрәк, биеклеге- 1.3 м) , куакларның зарарланган һәм юкка чыгарылган һәр саны исәпкә алына, кубик күләмдә санала.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
27.04.2018 ел, 324 нче санлы карарына
кушымта №1

Ылыслы агачлар

| Агачның төре | Бәясе (сумнарда) кәүсә диаметры 12 см һәм аннан күбрәк булган ылыслы агачлар өчен | Бәясе (сумнарда) кәүсә диаметры 12 смдан артмаган ылыслы агачлар өчен |
|---|---|---|
| Агач материаллары әзерләү рөхсәт ителми торган агачлар | 11200 | 9800 |
| нарат | 2800 | 1900 |
| карагач | 2200 | 1500 |
| Чыршы, ак чыршы | 2500 | 1700 |

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
27.04.2018 ел, 324 нче санлы карарына
кушымта № 2

башка торле агачлар

| Агачның төре | Бәясе (сумнарда) кәүсә диаметры 16 см һәм аннан күбрәк булган ылыслы агачлар өчен | Бәясе (сумнарда) кәүсә диаметры 16 смдан артмаган ылыслы агачлар өчен |
|---|---|---|
| Агач материаллары әзерләү рөхсәт ителми торган агачлар | 11200 | 9800 |
| Имән,корычагач,өрәңге | 8300 | 5800 |
| каен | 1400 | 980 |
| Зирек (кара төре), күг агач, элмә агачы, юкә | 800 | 600 |
| Усак, зирек (ак төре), тирәк | 300 | 200 |
| Башка төрләр | 200 | 150 |

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
27.04.2018 ел, 324 нче номерлы карарына
кушымта № 3

куаклар

| куакның төре | Бәясе (сумнарда) ылыслы һәм башка төр куакларның һәр төбе өчен |
|---|---|
| Агач материаллары әзерләү рөхсәт ителми торган куаклар | 550 |
| Башка төрләләр | 400 |